БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

ТАТАРСТАН ЯШЬЛӘРЕ

№ 144


(8260)

СИШӘМБЕ

5 декабрь, 1989 ел

Бәясе 2 тиен.

● ВЛКСМның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ ОРГАНЫ ● 1920 ЕЛНЫҢ 22 ЯНВАРЕННАН БИРЛЕ ЧЫГА ●



КОМСОМОЛ КОНФЕРЕНЦИЯЛӘРЕ

Әлмәт. XX шәһәр отчет-сайлау комсомол конференциясе булды. Отчет доклады белән ВЛКСМ шәһәр комитетының беренче секретаре Фоат Комаров чыкты.

Шәһәр комитетының беренче секретаре итеп — Фоат Комаров, икенче секретарь итеп — Сергей Брусов, укучы-яшьләр белән эшләү буенча секретарь итеп — Ирина Киселева, авыл яшьләре белән эшләү буенча секретарь итеп Анатолий Анисимов сайланды.

• • •

Лениногорск. XIX шәһәр отчет-сайлау комсомол конференциясе булды. Отчет доклады белән ВЛКСМ шәһәр комитетының беренче секретаре Алик Сәлимов чыкты.

Шәһәр комитетының беренче секретаре [illegible] Рамил [illegible] Сергей Степанов, укучы-яшьләр белән эшләү буенча секретарь итеп Фәния Минкина сайланды.

• • •

Мамадыш. XXXIV район отчет-сайлау комсомол конференциясе булды. Отчет доклады белән ВЛКСМ райкомының беренче секретаре Рөстәм Хуҗаҗанов чыкты.

Район комитетының беренче секретаре итеп — Илшат Зиннәтуллин, икенче секретарь итеп — Резидә Мөхәммәтҗанова, укучы-яшьләр белән эшләү буенча секретарь итеп Павел Смирнов сайланды.

• • •

Баулы. XXXIII район отчет-сайлау комсомол конференциясе булды. Отчет доклады белән ВЛКСМ райкомының беренче секретаре Марсель Фәхриев чыкты.

Район комитетының беренче секретаре итеп — Марсель Фәхриев, икенче секретарь итеп — Евгений Лидер, укучы-яшьләр белән эшләү буенча секретарь итеп Галина Осипова сайланды.

• • •

Минзәлә. XXXV район отчет-сайлау комсомол конференциясе булды. Отчет доклады белән ВЛКСМ райкомының беренче секретаре Николай Зыков чыкты.

Район комитетының беренче секретаре итеп — Люция Гафурова, икенче секретарь итеп — Иван Смирнов, укучы-яшьләр белән эшләү буенча секретарь итеп Татьяна Петрова сайланды.

• • •

Чаллы. Тукай районы. VII район отчет-сайлау комсомол конференциясе булды. Отчет доклады белән ВЛКСМ райкомының беренче секретаре Равил Галимов чыкты.

Район комитетының беренче секретаре итеп — Равил Галимов, икенче секретарь итеп — Виктор Белов, укучы-яшьләр белән эшләү буенча секретарь итеп Зөлфия Нигъмәтуллина сайланды.

● *Синең замандашың* ●



✦

Чөгендер плантацияләрен эшкәртү гомер-гомергә индивидуаль подряд алымы нигезендә башкарылып килде. Монда, әлбәттә, чәчү, рәт араларын эшкәртү механизатор җаваплылыгына тапшырыла иде. Ә менә Апас районының «Ракета» колхозында Кәбировлар гаиләсе хәзер бу эшләрнең барысын да үзләре башкара. 434 гектарлы участокны җиде кеше составындагы арендачылар коллективы тулысынча үз карамакларына алды: үзләре чәчтеләр, рәт араларын эшкәрттеләр, уңышын җыйдылар. Нәтиҗәдә һәр гектардан үстереп алынган уңыш 458 центнерга җитте. Арендачылар чөгендердән тыш башка төрле азык культураларын да үстерделәр. Алардан да мул уңыш чыкты.

Рәсемдә: арендачы Рамис Әбделхаков.

А. БИКТИМЕРОВ фотосы.

✦

АКТУАЛЬ ТЕМАГА

МЕҢНӘР

ЯКИ ҖИЛГӘ ОЧКАН ВӘГЪДӘ

Алар инде бүген берәүгә дә ышанмыйлар: бер төрле өйрәтеп, икенче төрле яшәүче әти-әниләренә дә, яшьләрне гел юлдан язган башкисәрләр итеп күрүче кешеләргә дә, партия, совет, комсомол һәм хокук саклау органнарына кереп оялаган, кеше мәнфәгатьләрен санга сукмаучы чиновникларга да һәм бу юлларны язучы газета хәбәрчесенә дә. Дөрес, аларның әле миңа: «Без инде сиңа да, синең газетаңа да ышанмыйбыз», — дип йөземә бәреп әйткәннәре булмады, әдәп саклауларыдыр. «Төркемгә оешып сугышып йөрүчеләрдә нинди әдәп ул?» — дип каршы төшәргә ашыкмагыз, төркемнәрнең дә төрлесе бар. Бу очракта сүз — алтмыштан артык яшь кешене берләштергән Зорге урамы төркеме турында. Хәер, укучыларның күбесе алар хакында белә инде. Газетабызның үткән елгы санында басылган «Бозкра уртасында» дигән язма яшүсмерләрнең ике елдан бирле ташландык подвалда үзләренә спорт белән шөгыльләну урыны оештыра алмый интегүләре турында иде. Мәкалә басылып чыккач та, төп «геройларның» берсе — ВЛКСМның Совет райкомы беренче секретаре Валерий Зәйнетдинов белән элемтәгә кердем. Бу төркем яшьләренең вәгъдәсез, җәнҗалчы булулары, берни эшләргә теләмәүләре, һәрвакыт канәгатьсезлек белдерүче иждивенчылар икәнлеген аңардан ишетеп белдем. Яшьләр белән күп тапкырлар очрашып, хәлләрен якыннан белмәгән, төрле оешмаларга йөреп түземлелек күнекмәләре алмаган булсам, бәлки, ышанган да булыр идем секретарьның сүзләренә. Төзек сөйли Валерий, ышандырырлык итеп сөйли. Юкка гына яшьләр аңа шулкадәр вакыт өмет баглап йөрмәгәннәр икән. Микрорайон яшьләрен матур киләчәк көткәнлегенә мине дә ышандырды Валерий: «Мартта я апрельдә, дөресрәге, июнь аенда, Зорге урамындагы хоккей тартмачыгы урынына җыелма спорт бинасы төзеләчәк». Ул чакта март-апрельгә, бигрәк тә июньгә җитәргә ярыйсы ук вакыт бар иде. Шулай да тынычландырды секретарьның сүзләре. Иң мөһиме — ничә еллар типкедә йөргән урам яшьләренең шөгыльләнер урыннары булачак. Димәк, шәһәребездә аз булса да киеренкелек кими, бәрелеш-сугышлар азая. Комсомол райкомы җитәкчесе авызыннан әйтелгән бу сүзләргә яшьләр дә сөенде. «Газета аша вәгъдә биреп, үтәми калганнары булмады әле моңарчы, — диделәр алар, һаман да үз спорт корылмалары буласына ышанып җитмичә. — Карарбыз, вакыт күрсәтер».

Әйе, ашыгыбрак тынычланганбыз икән шул. Яшүсмерләрнең икеләнү-шикләнүләре дә юкка гына булмаган: июньдә дә, аннан соңрак та Зорге урамында спорт корылмасын төзүчеләр күренмәде. «Аның шулай буласы билгеле иде бит, — диделәр егетләр мыскыллы елмаеп. — Өсләреннән төшерер өчен генә сөйли алар...» Бу юлы мин дәшмәдем: туры сүзгә җавап юк. Нәрсә диярге? Моңарчы торгынлыкта яшәдек дип акланырга да урын калмады — үзгәртеп кора башланганыбызга дүрт елдан артык вакыт үтеп китте. Демократия, хәбәрдарлыкны киңрәк кулланырга кирәк дип юатыргамы? Торгынлык чорында «башлап җырлаган» җитәкчеләрнең бүген дә шул ук урында калуларын, ләкин заман таләпләренә туры китереп «сайрауларын» алар болай да яхшы белә. Үзгәртеп коруның ни хәлдә булуын алар үзләрен камап алган кечкенә һәм зур начальникларның эшләреннән чыгып бәялиләр.

Яшүсмерләр тарафыннан кылына торган барлык җинаятьләрне дә әнә шулай спорт корылмалары төзеп яки төрле түгәрәкләр оештырып кына булдырмый калырга мөмкин дигән уйдан ерак торам мин. Ләкин «Казан феномены»н хокук саклау органнары көченә таянып, катгый чаралар күрү юлы белән генә җиңәргә була дигән фикернең дөреслегенә дә ышанмыйм. Без моңарчы да нәтиҗәләр белән җитәрлек көрәштек. Сәбәпләрне ачыкламыйча, аларны булдырмау хәстәрен күрмичә, проблеманы хәл итеп булмаячак.

Район отчет-сайлау комсомол конференцияләренең берсендә «Яшүсмер» берләшмәсе директоры Татьяна Абринина чыгышын тыңларга туры килде. Бу берләшмә ВЛКСМның Казан шәһәр комитеты каршында үткән ел оештырылган иде. Күп эш башкаралар андагы энтузиастлар. Киләчәккә зур планнары бар, ирешкән уңышлары җитәрлек. Ләкин директор берләшмәдә яшүсмерләр белән эшләүче 200 кешегә түләр өчен 1990 елда акча юклыгы турында борчылып сөйләде. Бер генә оешма да бирергә теләми икән аны. Проблема белән шөгыльләнергә тиешле оешмалар җитеп ашкан, ә менә эш материаль ярдәмгә килеп терәлгәч, алар берәм-берәм сәбәп эзли башлыйлар. Шул исәптән ВЛКСМның Совет райкомы да. Үз аппаратын ашатырга райкомның елына ничә мең сум тотканын чамалавы кыен түгел. Ә бәлки, эш өчен акча табалмый интегүчеләргә шушы меңнәрне тәкъдим итәргә кирәктер. Эзли башласаң, Казан шәһәре комсомол оешмасының структурасын гадиләштереп кенә дә күп меңнәр табарга булыр иде. Чыннан да, эш күрсәтә алмаган бюрократларны кайчанга кадәр ашатырга була?!

Ә әлегә барысы да искечә. Шәһәрдә яшүсмерләр җинаяте белән көрәшү буенча күпсанлы комиссияләр төзелә, чаралар билгеләнә. Шуңа да карамастан җинаятьчелек кимеми. Быелның ун аенда гына да, үткән елның шул ук вакыты белән чагыштырганда, үсмерләр җинаяте 36 процентка арткан. Шушы процентларга Зорге урамында кая барырга, ни белән шөгыльләнергә белми аптырап йөрүче төркем яшьләре дә өстәлмәс дип ышандырып булмый.

Миңназыйм СӘФӘРОВ, журналист.

ЯҢАЛЫКЛАР

Бөтенсоюз семинары

Узган атнада Рига шәһәрендә «Латвия. Үзгәртеп кору проблемалары» дигән темага Бөтенсоюз политик семинары булып узды. Анда ВЛКСМның өлкә, край комитетлары секретарьлары, яшьләр газеталары редакторлары катнашты.

Өч көн дәвам иткән семинар барышында кунаклар Балтик буе республикаларының экономик хәле, милли проблемалары белән таныштылар, күренекле галимнәрнең, партия-совет работникларының чыгышларын тыңладылар. Латвия ЛКСМ Үзәк Комитетында, Рига шәһәре предприятиеләрендә, авыл районнарында булган очрашулар шулай ук семинарда катнашучыларда зур кызыксыну уятты.

Кызыклы очрашу

Кичә газета-журналлар нәшриятының конференц-залында «Комсомольская правда» газетасы редакторы Владислав Фронин республикабыз матбугаты журналистлары белән очрашты.

«Комсомольская правда» газетасының зур популярлык казануы нәрсә белән аңлатыла? Газетаны чыгаруда ничә кеше катнаша? Матбугатның хуҗалык исәбе шартларында эшләвен ничек күз алдына китерәсез? В. Фронин журналистларның әлеге һәм башка күпсанлы сорауларына җавап бирде, яшьләр матбугаты өлкәсендәге аерым проблемаларга тукталды.

Казан дәүләт университетын тәмамлап тормышка юл алган журналист Чаллыда КамАЗ яшьләре белән очрашкан. Шундый ук очрашулар университет студентлары һәм Казандагы кайбер предприятие яшьләре белән дә уздырылачак.



УКУЧЫ — ГАЗЕТА — УКУЧЫ

КЕШЕЛӘР ҺӘМ ЯЗМЫШЛАР

ҮТКӘННӘР КАБАТЛАНМАСЫН!

Габделбәргә өч яшь тулганда әтисе дөнья куя. Үги әтисе дә бик озак яши алмый. Гает намазы укыткан дигән сылтау белән аның башын төрмәдә черетәләр. Аннары әнисе дә тиф авыруыннан терелә алмый.

Ләкин Габделбәр тормышның аяусыз җилләреннән сыгылып төшми. Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, педагогия училищесына укырга керә. Училищены уңышлы тәмамлагач, туган мәктәбенә тарих укытучысы булып кайта. Яшь укытучының тырышлыгын һәм сәләтен күреп, тиздән аны мәктәпнең уку-укыту бүлеге җитәкчесе итеп сайлыйлар.

Әмма тыныч тормышта күп эшли алмый. Европа өстендә фашист өләме җилферди башлагач, егетне Кызыл Армия сафларына алалар. Бөек Ватан сугышы башланганда ул отделение командиры була. Каты сугышларда катнашып, Мәскәүгә кадәр чигенә.

Мәскәү янындагы бәрелешләрнең берсендә каты яраланып, Габделбәр биш ай буе госпитальдә ята. Терелгәннән соң янә сугышка. Бу юлы Сталинградка эләгә... Днепропетровск янында барган сугышларның берсе аның өчен аяныч тәмамлана— контузияләнеп, дошман кулына эләгә.

Менә кайда икән ул тамуг газаплары!.. Днепропетровск төрмәсенең кара цемент идәненә җәелгән салам мыжлаган бетләрдән селкенеп тора. Ләкин бу ятакка ятып булмый, чөнки басып торырга да урын җитми...

Ә иртә белән ач, ялангач әсирләргә тачка белән кирпеч ташыталар. Һәр 150—200 метр саен камчылы сакчы тора. Алар яннарыннан үтүче әсирләрнең ялангач тәннәренә сугалар. Ә инде кансызлыгы белән даны таралган «мастер» Блюм кадаклы-дагалы итеге белән арт якка тибә. Әгәр дә егылсаң, сине типкәләү, камчылау китә.

«Ничек кенә булмасын, дошман тозагыннан котылырга, бу мәхшәрдән качарга! Ничек кенә булмасын, күргән мәсхәрәләр өчен дошманнан үч алырга!» — дигән уй бертуктаусыз Габделбәрнең башын бораулый... Бәхеткә, җай да килеп чыга. Тиздән әсирләрне Франция җиренә күчерәләр. Монда конвой үз эшенә әллә ни зур игътибар бирми. Шуннан файдаланып, төнлә этап белән барганда кача ул. Франция партизаннары — «маки»ларга кушылып, яңадан көрәшчеләр сафына баса.

Сугыш тәмамланганнан соң Сербест шәһәрендә КГБ органнары тарафыннан тикшерелгәч, берникадәр вакыт Совет Армиясе сафларында хезмәт итә, аннары демобилизацияләнеп туган якларына кайта.

Могҗиза белән генә исән калган солдатның хәсрәттән йөрәге телгәләнүе, җан сыкравы, бәгырь әрнүе моның белән генә бетсә икән. Юк шул, аның әле тагын да газапланыр көннәре алда икән. Әсирлектә булган дип ят-үги күрү, атна саен военкоматка, милициягә чакырып, мыскыл итә-итә сорау алулар, үз һөнәре буенча эшкә алмау, һәр адымын күзәтүләр...

Көннәрдән бер көнне аны, тырыш укытучыны, местком председателе итеп сайлыйлар. Җиң сызганып эшкә керешкәч, аның әсир булганын искә төшереп, башка кешене «сайлаталар». Райбашкарма комитеты секретаре урынына тәкъдим ителгәч, тагын шундый ук хәл кабатлана.

Ярар, фашистлар сине җәзалап, мыскыл итсеннәр, ди. Ә менә ни өчен сине Ватаныңда рәнҗетәләр соң?..

Дөрес, сугышта төрле хәлләр булган. Сатлыкҗан кешеләр дә җитәрлек очраган. Ләкин тикшереп тормыйча гына меңләгән-миллионлаган кешегә «ышанычны югалткан» дигән ярлык тагу бер кысага да сыймый.

Безнең строебызның гадел булуына шик тудырмас өчен, ул үзенең әрнүләрен, ачы кичерешләрен беркем белән дә уртаклашмый.

Гаделлек авырлыклар белән булса да җиңде. Габделбәр яңадан яраткан һөнәре буенча 40 елдан артык намус белән хезмәт итте. Дәүләт алдында ышанычсызлар сафында йөрсә дә, авыл халкы алдында лаеклы абруй казанды. Хәзер инде үзе: «Ул куркыныч еллар кабатланмасын өчен үткәннәрем хакында тулысынча, яшермичә сөйләргә булдым», — ди.

Рәүф ХӘЙРУЛЛИН,
сугыш һәм хезмәт ветераны.

Казан.





Васильево поселогындагы бу бина элек җимерек хәлдә иде. Хәзер анда Татарстан Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү министрлыгының «Волга» санаторие эшли башлады. Биредә дәваланучылар өчен барлык уңайлыклары булган кабинетлар җиһазландырылган. Профилакторийда ял итәргә һәм сәламәтлекләрен ныгытырга теләүчеләрне һәрвакыт якты йөз белән каршы алалар. Дәваланучылар арасында министрлык хезмәткәрләре генә түгел, республикабыз районнарыннан килүчеләр дә бар.

Профилакторийда эшләүчеләрнең киләчәккә планнары тагын да зуррак. Дәвалану кабинетларын киңәйтү, яңа корпуслар төзү күздә тотыла.

Рәсемдә: Нина Филюхина су массажы үткәрә; врач Люция Закирова.

Ш. АБДЮШЕВ фотолары.



Льготалар турында

▲ Хөрмәтле редакция! Газетаның 95 нче санында хатын-кызларга яңа льготалар турында хәбәр басылган иде. Шул хакта тулырак аңлатсагыз иде. Ул льгота 1989 елның декабрь аеннан башлап бала тудырган хатын-кызларга гына кагыламы?

АПТУКОВА.
Пермь өлкәсе,
Барда районы,
Аклуш авылы.

СССР Министрлар Советы һәм ВЦСПСның 1989 ел, 22 август карары нигезендә бала карау өчен түләүле ял балага 1,5 яшь булганчы озайтылды. Бу карар 1989 елның 1 декабреннән, ә сезнең өлкәдә 1990 елның 1 июленнән гамәлгә керә.

Моннан тыш, 1989 елның 1 декабреннән башлап бала карау өчен бирелә торган түләүсез ял бала өч яшькә җиткәнче арттырыла. Бу өстәмә ял өзлексез хезмәт стажына һәм белгечлек буенча стажга кертелә. 1989 елның 1 декабрена балаларына өч яшь тулмаган барлык хатын-кызлар бу өстәмә ялны алырга хокуклы.

Ш. ХӨСНЕТДИНОВ,
Профсоюзларның Татарстан өлкә советы юрисконсульты.

• • •

▲ Мин беренче балам белән түләүсез ялда вакытта икенче баламны таптым. Миңа декрет акчасы түләнәме һәм нинди тәртиптә?

НИГЪМӘТҖАНОВА.
Казан.

Бала карау өчен бирелә торган түләүсез ялда вакытта бала тапкан очракта, йөклелек һәм бала табу буенча пособие больничный листта күрсәтелгән бөтен көннәр өчен түләнә.

Бу вакытта йөклелек һәм бала табу буенча пособие, элек билгеләнгәнчә, уртача хезмәт хакыннан түгел, ә бәлки оклад яки тариф ставкасыннан чыгып исәпләнә.

А. АБДУЛКАДЫЙРОВ,
Агропромышленность комплексы работниклары профсоюзының Татарстан өлкә комитеты председателе.

Күпер салынырмы?

▲ Казаннан Чистайга машиналар рәхәтләнеп йөри алмый — Кама аша күпер юк. Кайчан да булса Кама аша күпер төзелерме?

З. САФИН.
Казан.

1988 елның декабрендә РСФСР Министрлар Советы Казан — Чистай — Бөгелмә юлында, Сорочьи Горы авылы янында Кама аша күпер төзелешенең РСФСР Автомобиль юллары төзелеше министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән техник-экономик нигезләмәсен раслады. Бу документ түбәндәге техник-экономик күрсәткечләрне эченә ала: кичүнең тулаем озынлыгы 18 километр, шул исәптән Кама аша үтә торган өлешенең озынлыгы 1,2 километр.

Күпер төзелешен башлау унөченче бишьеллыкка исәпләнгән.

Н. ЛЕКАРЕВ,
ТАССР Госстрое председателе урынбасары.

ТАРИХКА БЕР КАРАШ

Мәгърифәт учагы

Мин быел җәй Оренбург шәһәрендә булдым. Анда татарларның Октябрьгә кадәрге мәдәнияте, сәясәте һәм мәгарифе белән таныштым.

Бу язмамны «Хөсәения» мәдрәсәсенә багышлыйм. Моның язылуын «Татарстан яшьләре» газетасындагы (№ 91, 1 август, 1989 ел) «Мәдрәсә: мәгърифәт учагымы, наданлык оясымы?» дигән мәкалә дә тизләтте. Сүз уңаеннан шуны да әйтим: без мәдрәсәне наданлык, караңгылык оясы дип тәрбияләнеп үстек. Бу фикер миндә шушы көннәргә кадәр яшәде. Ә менә Хөсәения мәдрәсәсенең тарихы белән танышкач фикерләр үзгәрде.

«Хөсәения» мәдрәсәсе 1889 елда бертуган Әхмәт һәм Мәхмүт Хөсәенов дигән байлар тарафыннан ачылган. Ул мәдрәсә генә түгел, ә укыту комбинаты да булган. Анда баланы 14 ел укытканнар. Сигез яшендә беренче класска кергән бала башлангыч, урта, югары белемне дә шушында алган. Укытучылар мәдрәсә каршындагы интернатта яшәгәннәр. Ашау-эчү, уку, дәреслекләр, интернатта яшәү бушлай булган. Мәдрәсәдә аш пешерүче, хуҗалык мөдире, врач, фельдшерлар эшләгән.

Уку йортының барлык чыгымнарын Хөсәеновлар һәм Рәмиевләр финанслаган.

Безнең әдәбиятта байларга начар яктан гына урын бирелеп килә. Ә алар арасында әнә шундый мәдәният, мәгариф, фән өчен акчаларын кызганмаучылар да булган.

Дин, шәригать белемнәре белән бергә, шәкертләргә татар теле, тарих, география, физика, сызым, рус теле, гарәп теле, геометрия, тригонометрия, арифметика, астрономия, психология, логика, фәлсәфә, хокук нигезләре, гигиена һәм медицина, политэкономия һәм сәүдә эше, бухгалтерия, бала тәрбияләү, немец теле, иран теле, педагогика, табигать белеме, химия дәресләре кергән. Соңгысы ул вакытта Россиядәге гимназияләрдә дә укытылган. Мәдрәсәдә укулар кабинет системасы белән алып барылган. Шулай ук мәдрәсәдә бай китапханә, музей, түгәрәкләр эшләгән. Шуның өчен аның шәкертләре белемле, алдынгы карашлы булганнар.

Оренбургта чыга торган реакцион карашлы «Дин вә мәгыйшәт» журналы болай дип язган: «Хөсәения» мәдрәсәсеннән бер елга түгел, хәтта ун елга да бер мулла чыкмый. Дини бәйрәмнәр вакытында «Хөсәения» шәкертләре Гоголь кичәләре үткәргәннәр һәм спектакльләр куйганнар». (Оренбург, 1908 ел, № 18).

Мәдрәсәдә татар телен һәм әдәбиятын укытуга зур әһәмият биргәннәр. Моны атаклы язучылар, шагыйрьләр, тәнкыйтьчеләр, газета һәм журнал чыгаручылар укыткан. Алар түбәндәгеләр: Риза Фәхретдинов, Сәгыйть Рәмиев, Сәгыйть Сүнчәләй, Шәриф Камал, Җамал Вәлиди, Фатих Кәримов, Шәраф Бурнаш, Техвәт Ченәкәй һ. б.

Туган телдә сөйләнә торган иң яхшы шигырьгә ел саен конкурс үткәрелгән.

Күчерелеш һәм чыгарылыш имтиханнарында күп кеше катнашкан.

Октябрь революциясен мәдрәсә укучылары һәм күп кенә укытучылары шатланып каршылаганнар. Колчак, Дутов отрядларын һәм басмачыларны тар-мар итүдә шәкертләрдән байтак кеше катнашкан. I һәм V революцион армиянең политбүлекләрендә «Хөсәения»нең элеккеге шәкертләре хезмәт иткән.

Бу уку йортын тәмамлаучылар арасыннан дәүләт эшлеклеләре, галимнәр, язучылар, шагыйрьләр, журналистлар, редакторлар, театр, балалар йортлары, совет мәктәпләре һәм вузлары укытучылары чыккан. Мәсәлән, ТАССР халык мәгарифе комиссарлары Шәһит Әхмәдиев, ТАССР Верховный суды председателе Хөсәен Богданов, РСФСРның һәм ТАССРның атказанган фән эшлеклесе профессор Мидхәт Фәйзуллин һәм башкалар—«Хөсәения» мәдрәсәсендә белем алган кешеләр.

Октябрьдән соң «Хөсәения» педагоглары Оренбург һәм Бохарадагы беренче губерна совет-партия мәктәбе укытучылары булып эшләгәннәр. 1919-20 нче уку елына мәдрәсә татар халык мәгарифе институты итеп үзгәртелә. Соңыннан «Хөсәения» базасында башкорт, казах, көнчыгыш халык мәгарифе институтлары төзелә. Аларда «Хөсәения» укытучылары дәрес бирә. «Хөсәения» 32 ел эшли. Аның укытучылары һәм укучылары милли мәдәниятне күтәрүгә зур өлеш кертәләр.

Хәзер элеккеге «Хөсәения» мәдрәсәсе бинасында Оренбург авыл хуҗалыгы институтының агрономия факультеты урнашкан.

Мөнәвәр ЮНЫСОВ,
укытучы.

Апас районы.

Хуҗа булырга өйрәнәсе иде

Һәр поселокның үзенә күрә бер тарихы, үткәне була. Мин бу язмамда үзебез яши торган Нагорный поселогы турында сөйләргә телим. Миңа аның һәр ташы таныш. Заманында ул Чыңгыз дип йөртелгән бер урамлы кечкенә генә авыл иде әле. Урамның нәкъ уртасында бер күл һәм кое бар иде. Хәтеремдә, поселок барлыкка килгәч, кешеләр ул коега һәм күлгә игътибар итми башладылар. Ул гына да түгел, анда бөтен ташландык, чүп-чар тутырыла башлады. Һәм тиз арада күл урынында чүплек пәйда булды.

Кеше дигәнең бик кызык бит ул. Шәһәрләштеме, табигатьне саклауны оныта. Бу юлы да шулай булды.

Кеше рәхәткә чыдамый, михнәткә чыдый, диләр. Ирексездән кабат-кабат шушы хакыйкатьне искә төшерәм. Инде бүгенге көндә күп йортларга җылы үткәрелгән, газ кертелгән, башка төрле уңайлыклар бар. Әмма кешеләр чисталык турында үз ишегалдында гына кайгырта. Әз генә читкә чыктымы, иясез территория башлана. Күрәсең, хосусый милекчелек психологиясе шуңа этәрә кешене. Ә бу психология күпләрдә яши әле.

Менә шушы хәлләргә йөрәк әрни. Поселок урамнары хуҗасыз, ташландык хәлдә. Почтальоннар зарлана. Узып йөрүчеләр зарлана. Кешеләрне киңрәк масштабта уйланырга ничегрәк өйрәтергә икән?

Рәүф ХӨСНЕТДИНОВ,
(Штаттан тыш хәбәрчебез).

ӘДӘБИ ФОНД: ҮТКӘНЕ, БҮГЕНГЕСЕ, КИЛӘЧӘГЕ

„Максатыбыз — нәтиҗәлелек"

Билгеле булганча, быел ноябрь аенда Россия язучыларының Әдәби фонды оештырылуга — 130 ел, аның Татарстандагы оешмасы эшли башлауга 55 ел тулды. Шул уңайдан газетабыз хәбәрчесе СССР Язучылар союзы Әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры, РСФСР Әдәби фонды идарәсе әгъзасы, шагыйрь һәм публицист, Хөсәен Ямашев исемендәге республика премиясе лауреаты **Шаһинур МОСТАФИН** белән очрашты һәм аңа укучыларыбызны кызыксындырган берничә сорау белән мөрәҗәгать итте.

— Иң элек безне Әдәби фондның ничек барлыкка килүе, аның үзенчәлекле тарихы белән таныштырсагыз иде.

— Мондый фондның кирәклеге турында беренче фикер 1856 елда күренекле тәнкыйтьче-язучы А. В. Дружинин тарафыннан әйтелә һәм рус әдәбияты классиклары тарафыннан бертавыштан хуплана. Әлеге фондны оештыруда И. С. Тургенев, Л. Н. Толстой, Н. А. Некрасов, Н. Г. Чернышевский, П. В. Анненков, К. Д. Кавелин, А. В. Никитенко кебек атаклы каләм осталары, җәмәгать эшлеклеләре башлап йөри. Нәтиҗәдә 1859 елның 8 ноябрендә фондны оештыручыларның беренче җыелышы уздырыла. Һәм шунда Россиядә беренче тапкыр Әдәби фондның оешуы турында рәсми төстә белдерелә. Фондның беренче җитәкчесе итеп күренекле язучы һәм сәяхәтче Егор Ковалевский сайлана.

Шунысы кызыклы һәм гыйбрәтле: фондны оештыруга үзләре материаль яктан яхшы тәэмин ителгән язучылар, галимнәр, мәгърифәтчеләр зур булышлык, олы кайгыртучанлык күрсәтәләр. Алар авыр шартларда, матди яктан мохтаҗлыкта яшәүче талантларга ярдәм кулын бик теләп сузалар. Фонд шулай ук үлгән язучыларның, галимнәрнең, декабристларның гаиләләренә даими булышлык итеп тора: пособиеләр бирә, пенсияләр билгели, ятимнәрне үз хисабына махсус уку йортларына урнаштыра, кирәк чакта дәваланырга җибәрә. Җыеп кына әйткәндә, мин Әдәби фондны шәфкатьлелек оешмасы дияр идем. Чөнки ул оешуының беренче көннәреннән алып бүгенгәчә шул изге миссияне башкара.

— СССР Әдәби фонды һәм аның эшчәнлеге турында да сөйләп үтсәгез иде.

— Совет язучыларының Беренче съезды алдыннан гына, 1934 елның 28 июлендә, СССР Халык Комиссарлары Советы СССР Әдәби фондын оештыру турында махсус карар кабул итә.

СССР Әдәби фонды идарәсенең иң беренче рәисе итеп атаклы язучы Всеволод Иванов сайлана. Идарә, президиум һәм ревкомиссия составларына әгъзалар итеп халыкның олы ышанычын-ихтирамын казанган каләм осталары кертелә...

Бүгенге көндә СССР Әдәби фондын (ул ун меңгә якын әгъзаны берләштерә) танылган язучы Николай Горбачев җитәкли. Хәзерге вакытта СССР Әдәби фондының барлык союздаш республикаларда һәм язучылар саны күбрәк булган кайбер республикаларда (мәсәлән, Башкортстан, Дагстан, Чувашия һ. б.) аерым бүлекләре бар.

Безнең Татарстан Язучылар оешмасы сан ягыннан Россия Федерациясе күләмендә Мәскәү белән Ленинград оешмаларыннан гына калыша. Хәтта кайбер союздаш республикаларныкыннан да күбрәк бездә Әдәби фонд әгъзалары (чагыштыру өчен: Төркмәнстанда — 154, Таҗикстанда — 157 кеше). Шушы ел башында фондның Татарстан бүлегендә 186 әгъза исәпләнсә, ноябрь аенда бу сан 197 гә җитте.

— Фонд нәрсә хисабына яши!

— Революциягә кадәр, башлангыч чорда, Әдәби фондка әгъзалар итеп язучылар белән берлектә галимнәр һәм мәгърифәтчеләр дә кабул ителгән. Аларның һәркайсы ел саен 10 сумнан да ким булмаган күләмдә взнос түләп торырга тиеш булган. Мөмкинлекләре зуррак булганнары исә фонд кассасына йөзләрчә, меңнәрчә сум акча керткәннәр. Ул чор язучылары үзләре төрле кичәләр үткәрүдән, спектакльләр куюдан тупланган суммаларны да фонд кассасына тапшырганнар.

Хәзер дә Әдәби фонд язучыларның взносларыннан файдалана (һәр кеше, элеккечә, елга 10 сум түли). Фонд файдасына шулай ук газета-журнал, китап нәшриятларыннан, тамаша учреждениеләреннән дә — алынган табыш хисабыннан — шактый акча күчерелә. Боларның һәммәсе Әдәби фондның материаль-финанс базасын ныгытуда ышанычлы чыганак булып тора.

— Газета укучыларны Әдәби фонд средстволарыннан ничек файдалануыгыз да кызыксындыра иде...

— Аларның һәммәсе, инде әйткәнебезчә, язучыларның яшәү һәм иҗат итү шартларын яхшыртуга, дәвалануга, ялларын файдалы итеп үткәрүгә һ. б. тотыла. Репрессияләнгән, яу кырында һәлак булган һәм сугыштан соң үлгән язучыларның гаиләләренә дә (алар барысы 89 гаилә) даими рәвештә материаль ярдәм күрсәтәбез. Пенсионер яисә хезмәт инвалидлары булган язучыларга (86 кешегә) шушы елның маеннан башлап ай саен, пенсияләренә өстәп пособиеләр бирәбез. Моңарчы III группа инвалид булган, әмма пенсия яше җитмәгән язучыларга пособие түләнми иде. Без моңа бик борчылып, үзебезнең каләмдәшләребезнең материаль яктан авыр хәлдә яшәүләрен конкрет мисалларда күрсәтеп, СССР һәм РСФСР Әдәби фондларына хатлар юлладык. Күптән түгел генә бу мәсьәлә дә уңай хәл ителде. Хәзер III группа инвалид булган язучыларыбыз да айга өстәмә рәвештә 100 сум күләмендә пособие ала алалар. Шулай ук пенсия яшенә җитмәгән профессиональ язучыларга да (теге яки бу оешмада, учреждение яисә предприятиедә эшләмәүче, әмма иҗат итү белән даими шөгыльләнүче каләмдәшләребезгә) быелдан башлап, ялларын файдалы итеп оештыру өчен, елга бер мәртәбә 150 сум күләмендә пособие түләнә башлады (моңарчы аларга, беркайда да эшләмиләр дип, түләүле ял бирелми иде). Язучыларның 8 яшькә җитмәгән балаларына пособиеләр түләүне башлап җибәрү дә быелгы шатлыклы яңалыкларның берсе.

Илебезнең төрле төбәкләрендәге иҗат йортларына, санаторийларга да без язучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын үзләре теләгән вакытта җибәрергә тырышабыз. Кагыйдә буларак, путевкалар өчен тиешле сумманың зур өлешен Әдәби фонд үзе түли. Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм инвалидларның юл йөрү чыгымнарын да Әдәби фонд үзе күтәрә. Хуҗалык исәбендәге поликлиника белән ике арада төзелгән килешү нигезендә (без тиешле сумманы ел башында ук өлеге оешмага күчереп куябыз), язучыларыбызга яхшы сыйфатлы медицина ярдәме күрсәтелә. Әдәби фонд әгъзаларына, вакытлыча хезмәткә сәләтләрен югалткан очракта, дүрт ай дәвамында (104 эш көне исәбеннән), Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәм инвалидларга биш айга хәтле (130 эш көне) — гонорарларының уртача күрсәткечләреннән чыгып, һәр көнгә 5 сумнан да ким булмаган, 10 сумнан да артмаган күләмдә — пособиеләр түләп торабыз.

Каләмдәшләребезгә иҗат итү өчен тиешле мөмкинлекләр тудырырга да омтылабыз. Яңа әсәрләрен язуда материаллар туплауда ярдәм итү максатыннан чыгып, Әдәби фонд әгъзаларына түләүле иҗат командировкалары бирелә, иҗат итү чорында пособиеләр түләнә.

Язучыларны соңгы юлга озату, каберләрен тәртипкә китерү чыгымнарын да Әдәби фонд үз өстенә ала.

— Әдәби фонд әгъзаларына, Язучылар союзы аппаратының төрле тармакларында эшләүчеләргә фатир алу җиңелрәк, диләр. Бу дөрес фикерме!

— Алай ук димәс идем. Дөрес, фатирлар алу өчен СССР һәм РСФСР Әдәби фондлары Татарстан бүлегенә ел саен диярлек средстволар бүлеп бирә. Әмма алар хәзергә җитәрлек күләмдә түгел әле. 1984—1988 елларда, мәсәлән, безгә фатирлар өчен 150 мең сум акча бирелде. Тик аңа карап хәл җиңеләймәде. Хәзерге вакытта безнең иҗат союзында 70 тән артык кеше (гаилә) фатир чиратында тора. Үтә кысан, уңайсыз шартларда яшәүче һәм иҗат эше белән шөгыльләнүче каләмдәшләребезнең күп булуы, әлбәттә, безнең һәммәбезне — Татарстан Язучылар союзы идарәсе белән Әдәби фонд идарәсен дә, партия һәм профсоюз оешмаларын да бик борчый. Һәм без бу кыен хәлдән чыгу юлларын күмәкләшеп эзлибез.

— Сезнең Әдәби фонд карамагында язучыларның «Аккош күле» дип исемләнгән иҗат йорты да бар бит әле. Анда хәлләр ничегрәк!

— Әлеге иҗат йортына нигез 1953 елда, ул чакта Татарстан Язучылар союзы идарәсе рәисе булган халык язучысы Гомәр ага Бәширов инициативасы белән салынган. Күп кенә язучыларыбыз биредә үзләренең халык тарафыннан киң танылган әсәрләрен иҗат иткәннәр. Еллар үтү белән биредәге йортларның барысы да диярлек искергән. Ярым җимерек хәлдә булганнары да бар. Шуны истә тотып, үткән елның көзендә, Татарстан Язучылар союзы идарәсе белән берлектә, без СССР Әдәби фондына, иҗат йортыбызга реконструкция үткәрү өчен средстволар бирүне сорап, хат белән мөрәҗәгать иттек. Мәскәүдән махсус комиссия килеп, иҗат йортының хәле белән танышканнан соң, безгә тиешле күләмдә сумма бирелде. Шушы ел башыннан иҗат йортында үзгәртеп кору эшләрен башлап җибәрдек. Үткән айлар эчендә иҗат йорты урнашкан мәйдан койма белән яхшылап әйләндереп алынды, берничә урында капкалар ясалды, юлларга комташ җәелде. Карабылчы йорты һәм язучылар өчен икешәр бүлмәле ике йорт төзелде. Мунча-сауна бинасы торгызылды... Болары эшнең башы гына әле. Тик безне эшнең барышы, төзелеш темплары һич тә канәгатьләндерми. Без ныклы материаль-техник базасы булган төзелеш оешмалары ярдәменә бик тә мохтаҗбыз...

— Оешмагызның 55 еллык юбилее уңае белән нәрсәләр әйтергә телисез!

— Иң элек Әдәби фонд әгъзаларын һәм Әдәби фонд системасында эшләгән һәркемне, Татарстан Язучылар союзы идарәсе рәисе Ринат Мөхәммәдиев һәм Әдәби фондның республика бүлеге идарәсе рәисе Әхсән Баянов иптәшләр белән берлектә, шушы истәлекле дата уңае белән чын күңелдән кайнар котлыйбыз һәм ныклы сәламәтлек, бәхетле тормыш телибез. Монысы, әлбәттә, исәннәр адресына — Әдәби фонд системасында озак еллар дәвамында нәтиҗәле эшләгән Афзал Шамов, Әхмәт Исхак, Азат Әхмәдуллин, Лерон Хәмидуллин, Әхмәт Рәшитов, Нәсимә Гобәйдуллина, Шаһидә Мәксудова, Гөлшат Зәйнашева, Маннур Саттаров, Надежда Кедрова, Клавдия Чеклуева, Әхмәт Гадел, Сафуан Муллагалиев, Шамил Мөхәммәтҗанов, Мәхмүт Билалов һ. б. иптәшләр адресына әйтелә. Ә инде вафат булганнарны, вакытсыз бу дөньядан киткәннәрне без зур хөрмәт, тирән юксыну хисләре белән искә алабыз. Болары, беренче чиратта, Әдәби фондның беренче җитәкчесе (уполномоченные) — шәхес культы корбаны Закир Сәмитовка, аннан соң эшләгән Халикъ Садри, Сөнгать Сафиуллин, Хәсән Сәрьян, Мәсгуть Шәрифуллин, Ринат Вахитовларга, «Аккош күле» иҗат йортының беренче коменданты Нәби Дәүлигә, бухгалтерия хезмәткәрләреннән — Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган шагыйрь Исхак Закировка һәм моннан берничә ел элек вакытсыз вафат булган Нурия Вәлиева кебек фидакарьләргә кагыла.

Бүгенге көндә дә безнең Әдәби фонд аппаратында чын мәгънәсендә үз эшләренең осталары булган кешеләр эшли. (Бу хакта Татарстанның халык язучысы Әмирхан ага Еники үзенең «Советская Татария» газетасына 1989 елның 24 мартында биргән интервьюсында да әйтеп үткән иде). Иҗат йорты буенча бухгалтер Вера Васильевна Рожкова, мәсәлән, инде чирек гасырга якын язучыларга игелекле хезмәт күрсәтә. Юбилей уңаеннан безнең идарә аны «СССР Әдәби фонды отличнигы» дигән мактаулы исемгә һәм «Хезмәт ветераны» медаленә тәкъдим итте. Бүлекнең өлкән бухгалтеры Диләфрүз Вахитова, хисапчы-кассир Дания Гайнетдинова, язучылар китапханәсе мөдире Римма Миңнуллина иптәшләр үзләренең өлгерлекләре, тапшырылган һәр эшне зур җаваплылык тоеп башкарулары белән аерылып торалар. Техничка Рәмилә Акмалиева, иҗат йорты коменданты Рөстәм Сабировлар да безнең системада озак еллар дәвамында эшлиләр.

Әмма эшебездә кимчелекләр дә бар әле. Кайбер язучыларны үз вакытында иҗат йортларына, санаторийларга путевкалар белән тәэмин итеп булмады. Өлкән яшьтәге каләмдәшләребезнең, инвалидларның өйләренә хәл-әхвәлләрен белү өчен сирәк барабыз. Әлмәт һәм Чаллы язучылары оешмаларындагы Әдәби фонд әгъзаларына, аларның ихтыяҗларына игътибарны тагын да арттыру сорала. Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубы эшчәнлеген дә тамырдан яхшыртасы бар. Төрле кичәләргә, очрашуларга халык бик аз йөри. Бүгенге көндә клубның директоры да юк. Без талантлы, инициативалы, татарча яхшы белгән яшьләрне яисә бу өлкәдә бай тәҗрибәсе булган өлкәннәрне Тукай клубына директор сайлап алу конкурсында актив катнашырга чакырабыз...

Эшне мөмкин кадәр нәтиҗәлерәк, файдалырак итеп оештырырга, кешеләргә мөмкин кадәр күбрәк шатлык бүләк итәргә — безнең төп максатыбыз әнә шундый. Иҗат союзына, Әдәби фондка йомышы төшеп килгән һәр кеше биредән күтәренке күңел, елмаюлы йөз белән китәрлек булсын...

— Әңгәмәгез өчен рәхмәт!

Әңгәмәне
Рифкать БИКЧУРОВ
үткәрде.

Мода еллап түгел, көнләп үзгәрә. Быел, мәсәлән, ГДР хатын-кызлары арасында «Ситилайн» прическалары популяр булды. Шундый прическа ясаткан хатын-кызлар, һичшиксез, тирә-юньдәгеләрнең, бигрәк тә ирләрнең, игътибарын үзенә җәлеп итә. Ачык һавада гына түгел, бәлки көзге, кышкы салкыннарда төрле эшләпә, бүрек кигәч тә әлеге прическаны бозмыйча сакларга була.

Рәсемдә: «Ситилайн» прическасының бер төре. Аны йөз-кыяфәткә карап үзгәртергә була.

АДН—ТАСС фотосы.

УКУЧЫ АДРЕС СОРЫЙ

Туган яктан китмә икән...


Миңа 28 яшь. Балтач районының Иске Чепья авылыннан. Шактый гына чит җирләрдә эшләп йөрергә туры килде һәм күптән түгел язмыш мине тагын да ераккарак ташлады. Сәбәбе бар. Узган ел әтием белән хатыным кунактан кайткан вакытта Арзамас станциясендә авариягә эләгеп һәлак булды... Хәзерге көндә туган якта туганнарым калмады. Әйтәсе килгән сүзем шул: Татарстанның берәр колхоз яисә совхозында терлекчелектә эшләргә теләр идем. Яшәп торырга тулай торак булса да ярый.

Күңелләрне өздереп җырлаган Айдар Фәйзрахманов тавышын ишетсәм, бүген үк очып кайтып җитәрмен төсле. Яшьләр авыллардан китеп, читтә эшләргә тырышалар. Туган ягыңны, туган авылыңны ташлап чыгып китмә икән, диясем килә андыйларга. Кая барсаң да өеп куймаганнар, кая барсаң да эшләргә кирәк. Безнең яктагы кебек сабантуйларны, милли моңлы җырларны, бездәгедәй саф сулы чишмәләрне башка җирдә эзләп таба алмыйсың. Үтенеп язган бу хатыма газета аша җавап аласым килә.

Гәрәй СӘЙДОВ.


Хабаровск крае,
Амурдагы Комсомольск шәһәре.

фотоинформация



Украина ССР. Симферопольдәге «Фотон» производство берләшмәсендә төсле телевизорларның яңа моделе — «Фотон-51 ТЦ-503 стерео» эшләнә башлады. Ул микропроцессорларга нигезләнгән санлы идарә пульты белән җиһазландырылган һәм «Пал», «Секам» системасындагы төрле төсле программаларны, шулай ук башка стандартларны да кабул итә ала.


Рәсемдә: ЭВМ операторы Н. Зелецкая яңа телевизорны күрсәтә.



Швейцария. Базендада үткәрелә торган традицион Европа сәгать һәм ювелир әйберләре күргәзмәсе елдан-ел үзенә күбрәк игътибар җәлеп итә.

Дөнья базарындагы кискен көндәшлек яңа техник һәм эстетик формалар эзләүгә этәрә. Швейцариянең атаклы сәгать фирмалары, боларны истә тотып, уникаль продукция җитештерәләр. Мондый сәгатьләр гадәттә бик аз чыгарыла һәм еш кына шәхси заказ буенча эшләнә.

Рәсемдә: циферблатларны төрлечә бизәү — базарны яулап алуда бер алым. «Моден Уотч» фирмасы, мәсәлән, шушындый символикалы сәгатьләр тәкъдим итә.



Краснодар крае. Таш кисү фабрикасы слесаре Алексей Журавлев Передовой станицасында яши. Сугыш аңа белем алырга комачаулаган. Ләкин шулай да Журавлев үзенең рационализаторлык һәм уйлап табу өлкәсендәге хезмәтләре белән дан тота. Аның иҗат җимешләре арасында мини-трактор, кыру станогы, йон эрләү һәм агач эшкәртү җайланмалары бар. Бигрәк тә «Тула-200» мотороллеры нигезендә эшләнгән өч көпчәкле трактор кызыксыну уята. Авыл хуҗалыгы эшләрендә ул менә дигән ярдәмче. Әлеге трактор җир дә сөрә, бәрәңге дә казый, әйбер дә ташый, җир дә эшкәртә.

Рәсемдә: А. Жур... ев үзенең тракторы белән.

ТАСС фотохроникасы.

Нәниләргә яңа театр

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры каршында оештырылган «Балачак» театр-студиясе үзенең эшчәнлеген башлавы турында инде хәбәр иткән идек. Бу — республикабыз мәдәнияты тормышында зур вакыйга. Театр-студия яшь тамашачыларга беренче спектаклен — драматург Т. Миңнуллин әсәре буенча куелган «Авыл эте Акбай» музыкаль комедиясен күрсәтте. Ниһаять, балаларның татар телендә үз театрлары, үз сәхнәләре булдырылды.

— Театр төзелгәндә үк кече зал балалар өчен дип күздә тотылган иде, — ди театрның баш режиссеры М. Сәлимҗанов. — Яшь артистларыбыз балаларга спектакльләр куюны үз өсләренә алырга теләк белдерделәр. Менә шулай итеп театрда бер студия барлыкка килде. Аңа «Балачак» дигән матур исем дә куштылар. Нәни тамашачылар өчен шундый студия оешу бик әйбәт күренеш. Уйлап карагыз: татар телендә яшь тамашачылар театры да, курчак театры да юк. «Балачак» менә шуларга башлангыч бирер дип өметләнәм һәм аңа уңышлар телим.

Кече залда барлыгы 150 урын. Студия беренче спектаклен күрсәткәндә аның тулы булмавы күңелдә беразшик тудырган иде. Юкка булган икән. Бәйрәм көннәрендә күрсәтелгән спектакль һәм «Шулай да булгалый» исемле театраль тамаша вакытында залда бер генә буш урын да юк иде. Димәк, яшь тамашачылар студияне инде бәяләп өлгергәннәр. Тагын бер деталь: кече залда спектакльләр рус теленә тәрҗемә ителми. Һәм моның кирәге дә юктыр. Татар телендә спектакль карау балаларга туган телләрен өйрәнүдә өстәмә бер дәрес бит.

Студиянең балаларга күрсәтер өчен сайлап алган беренче спектакле «Авыл эте Акбай» яхшы тәэсир калдырды. Беренче чиратта аның нәкъ менә балалар өчен язылуы сөендерде. Нәни тамашачыларның бу спектакльне ничек кабул итүләрен премьера барышында ук күрергә мөмкин иде. Алар сәхнәдә барган вакыйгаларга битараф булмыйча, әкият геройлары өчен борчылып та, шатланып та утырдылар. Спектакльнең тагын бер уңай ягы — аның шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек турында булуы. Янәшәбездә яшәүче этләргә, мәчеләргә мөнәсәбәтебез төрлечә, бу бигрәк тә шәһәрдә аеруча сизелә. Җылы өйләребездә диваннарда йоклаучы мәчеләр бар, юынтыкларда тамак туйдырып яшәүче ташландык этләр бар. «Безнең язмыш кешеләр кулында. Мәрхәмәтлерәк булсыннар иде. Кешеләр яхшы булса, без дә яхшы, алар начар булса, без дә начар». Сәхнәдәге этләр авызыннан чыккан бу сүзләр балалар күңеленә барып ирешә алса, алар шәфкатьлелек турында уйлансалар, студия үзен зур эш башкарган дип саный ала. Иртәгә никадәр баланың әйләнә-тирәбездәге хайваннарга, җанварларга мөнәсәбәте яхшы якка үзгәрәчәк. Гомумән алганда, җырга, музыкага бай булган әлеге спектакль олыларны да битараф калдырмый.

Хәзерге вакытта студия укучыларга кышкы каникул көннәрендә күрсәтер өчен яңа спектакль әзерли. Бу җәһәттән газета аша артистларның бер теләген белдерәсе килә. Балалар өчен иҗат ителгән сәхнә әсәрләре бик аз бездә. Студия драматургларга, язучыларга мөрәҗәгать итә: килегез, тәкъдим итегез әсәрләрегезне. Сүз уңаеннан тагын бер нәрсәне әйтеп үтәсе килә. Бәйрәм спектакльләрендә залда буш урыннар юк диган идем. Ә бәлкем, кышкы каникул көннәрендә спектакльләрне көндез театрның зур залында куяргадыр? Минемчә, моны эшләргә мөмкин. Теләге булган барлык балалар өчен спектакль карау мөмкинлеге туар, ә укытучылар каникул көннәрендә укучыларның мәктәпләрдән бергәләп килүен оештыра алырлар иде.

Татар дәүләт академия театрының яшь артистлары зур эшкә тотындылар һәм бик тә кирәкле эшкә. Балаларның үз театрларын булдыру — киләчәк буын турында чын мәгънәсендә кайгырту ул. Аларга бу изге омтылышларында уңышлар телик.

Р. НАСЫЙБУЛЛИН.

«ТАТАР ЭСТРАДАСЫ-89»

Хөрмәтле укучым! Янәшәдәге фотода «Татар эстрадасы-89» конкурсының афишасын һәм җиңеп чыгучыларга тапшырыр өчен әзерләнгән диплом белән медальне күрәсеңме? Диплом һәм медаль — Фатих Кәрим исемендәге премиянең билгеләре. Аларга кемнәр лаек булыр, моны 6 **декабрьдә** Казанның Цирк бинасында узачак ике концерт танытачак. Зона концертларында җиңеп чыккан җырчылар, нәфис сүз осталары бу көнне Казан тамашачысы һәм вәкаләтле жюри алдында осталыкларын күрсәтәчәкләр. Катнашучыларның саны бик күп — йөзгә җыела, шуңа күрә тамашачы белеп торсын: ике концертта катнашучы артистлар да төрле булачак. Оештыру группасы ике концертны да бердәй дәрәҗәдә кызыклы булачак дип ышандыра. Ә инде берьюлы икесен дә карарга түземлегебез җитәр дип уйлаучылар кичке биштән төнге унбер-уникенчегә кадәр жюрига көч биреп утыра алалар. Моның өчен аларга бары тик ике концертка да билет алырга гына кирәк. Тәнәфесләрдә ашап-эчеп, китап, пластинка, календарьлар сатып алырга, газетабызның стендларын карап йөрергә мөмкин, хөрмәтле дуслар!

Фотодагы тагын бер бүләккә — чиккән кулъяулыкларга да игътибар иткәнсеңдер, укучым. «Татарстан яшьләре»нең бер санында җырчы Гөлзада Сафиуллина конкурста җиңәчәк артистларга үзебезчә матур, сөйкемле бер бүләк — чигүле кулъяулыклар әзерләү тәкъдиме белән мөрәҗәгать иткән иде. Берничә укучыбыз бу тәкъдимне хуплап, редакциягә үзләре чиккән берсеннән-берсе матуррак кулъяулыклар җибәрде. Әлеге самими бүләкләргә кем ия буласын залдагы тамашачы үзе хәл итәр. Аларга яраткан җырчыларына, нәфис сүз осталарына үз бүләкләрен, призларын алып килеп тапшыру хокукы бирелә. Белмәссең, жюрига ошап бетмәгән башкаручының тыңлаучы күңелен билəве бар. Кайчакта тамашачы биргән бәя һәм бүләк иң кыйммәтле призлардан да кадерлерәк була ул.

Кыскасы, газетаның 70 еллыгына багышланган конкурсыбыз ахырына якынлашып килә. Ул, кадерле дуслар, сезнең белән бергә җыр, музыка, илһамлы сүз бәйрәменә әйләнсен. Концертларга рәхим итегез! Алар 17 һәм 20 сәгатьләрдә башлана.

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры. 5 декабрьдә 19 сәгатьтә — «Анюта», 6 декабрьдә 19 сәгатьтә — «Отелло».

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. 5 декабрьдә 19 сәгатьтә — «Ай тотылган төндә», 6 декабрьдә 19 сәгатьтә — «Булмас димә, дөнья бу!».

В. И. Качалов исемендәге Зур драма театры. 6 декабрьдә 19 сәгатьтә — «Безнең Декамерон».

К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры. 6 декабрьдә 19 сәгатьтә — «Мәкәрҗәгә барган идек».



«Татарстан». 9, 11-50, 14-40, 17-35 һәм 20 сәгать 30 минутта — «Бервакыт Америкада».

«Родина». 9, 10-45, 12-30, 14-15, 16, 17-50, 19-40 һәм 21 сәгать 30 минутта — «Ике ук».

«Спутник». 9 сәгатьтә — «Ника варисы», 10-20, 12-45, 14-40, 17-05, 17-30 һәм 21 сәгать 30 минутта — «Анна Дзаккеога ир бирегез».

«Идел». 9, 10-50, 12-40, 16-50, 18-40 һәм 21 сәгатьтә — «Йомшак вагон», 15 сәгатьтә — «Түбәдән адым».

«Звезда». 10-40, 12-30, 16-10, 18 һәм 20 сәгать 10 минутта — «Озата баручы», 14 сәгать 20 минутта — «Тап мине, Леня».

«Восток». 16-20, 18 һәм 20 сәгатьтә — «Мценск өязеннән леди Макбет».

«Комсомолец». 10, 11-50, 16, 17-50 һәм 20 сәгать 10 минутта — «Ике ук», 14 сәгать 30 минутта — «Вакыт хөкемдарлары».

«Мир». 11-30, 13-50, 16-10, 18-30 һәм 20 сәгать 50 минутта — «Рио кешесе».

Г. Тукай исемендәге кинотеатр. 9-30, 11-50, 16, 18-10 һәм 20 сәгать 10 минутта — «Рио кешесе», 14 сәгать 30 минутта — «Метичара — диңгез җәнлеге».

«Огонек». 14, 17 һәм 20 сәгатьтә — «Интеркыз».

«Факел». 10-20 һәм 14 сәгать 10 минутта — «Тотылмас үч алучылар», 12-10, 15-50, 18 һәм 20 сәгать 30 минутта — «Король гвардиясе укчысы Квентин Дорвард мажаралары».

«Костер». 9-30, 10-50 һәм 12 сәгать 30 минутта — «Ералаш», 13 сәгать 50 минутта — «Метичара — диңгез җәнлеге», 15 сәгать 30 минутта (абонемент) — «Җимерүче», 17-30 һәм 20 сәгать 10 минутта — «Интеркыз».

В. И. Ленин исемендәге Культура һәм техника сарае. 10, 12, 14-10, 16, 17-45, 19-30 һәм 21 сәгать 15 минутта — «Йомшак вагон».



Бүген, 5 декабрьдә, болытлы һава, явым-төшем, буран, күз күреме 1—2 километр. Көнбатыштан секундына 9—14 метр тизлектә җил. Температура Казанда — 1—3, Татарстанда 0 дән 5 градуска кадәр салкын. Юлларда бозлавык.

АДРЕС: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт, «Татарстан яшьләре» газетасы редакциясе.

ТЕЛЕФОННАР: редактор — 53-52-34, редактор урынбасары — 53-07-52, җаваплы секретарь — 53-07-58.

Бүлекләр: яшьләр проблемалары — 53-07-54, коммунистик тәрбия — 53-07-56, хатлар һәм социаль-көнкүреш проблемалары — 53-07-50, корректорлар, рәссам, фотограф — 53-07-48, белдерүләр — 53-38-92.

«Татарстан яшьләре» газетасы — ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты органы. Газета сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга.

* * *

Газета «Татарстан яшьләре» включена во Всесоюзный каталог газет и журналов («Список газет союзных республик» (Часть 1).

Индекс газеты — 54121.

Редактор Х. ГАЙНУЛЛИН.



ПФ 05366. КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясендә басылды. Казан, Декабристлар урамы, 2. Тираж 255.000. Заказ 3008.